КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 27 декабрь г.Казань № 1692

2023 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондыннан Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы бюджетына 2023 елның 25 июлендә көнкүреш газы шартлау нәтиҗәсендә зыян күргән Түбән Кама шәһәре, Вахитов проспекты, 11 йорт адресы буенча күпфатирлы торак йортта авария-торгызу эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән 2023 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондыннан Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы бюджетына 2023 елның 25 июлендә көнкүреш газы шартлау нәтиҗәсендә зыян күргән Түбән Кама шәһәре, Вахитов проспекты, 11 йорт адресы буенча күпфатирлы торак йортта авария-торгызу эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 27 декабрь, 1692 нче
карары белән расланды

2023 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондыннан Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы бюджетына 2023 елның 25 июлендә көнкүреш газы шартлау нәтиҗәсендә зыян күргән Түбән Кама шәһәре, Вахитов проспекты, 11 йорт адресы буенча күпфатирлы торак йортта авария-торгызу эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип 2023 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондыннан Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы (алга таба - Түбән Кама муниципаль районы) бюджетына 2023 елның 25 июлендә көнкүреш газы шартлау нәтиҗәсендә зыян күргән Түбән Кама шәһәре, Вахитов проспекты, 11 йорт адресы буенча күпфатирлы торак йортта авария-торгызу эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү механизмын билгели (алга таба - тиешенчә башка бюджетара трансфертлар, авария-торгызу эшләре, күпфатирлы йорт).

2. Бу Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчасы белән баш эш итүче булып Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (алга таба – Министрлык) тора.

3. Башка бюджетара трансфертлар 2023 елда әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Министрлыкка билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә.

4. Әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга бирелә торган башка бюджетара трансферт күләме билгеләнгән тәртиптә расланган авария-торгызу эшләрен башкаруга локаль смета исәбе нигезендә авария-торгызу эшләренең смета бәясе нигезендә билгеләнә.

5. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары:

авария-торгызу эшләре буенча чараларны гамәлгә ашыру өлешендә чыгым йөкләмәләрен билгели торган Түбән Кама муниципаль районының хокукый акты булу;

әлеге Тәртипнең 10 пункты нигезендә Министрлык һәм Түбән Кама муниципаль районы җирле үзидарәсенең вәкаләтле органы арасында башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү (алга таба – Килешү) төзү;

Россия Федерациясе Статистика буенча дәүләт комитетының «Капиталь төзелештәге эшләрне һәм ремонт-төзелеш эшләрен исәпкә алу буенча беренчел исәпкә алу документациясенең унификацияләнгән формаларын раслау турында» 1999 елның 11 ноябрендәге 100 номерлы карары белән расланган КС-2 дигән унификацияләнгән форма буенча башкарылган эшләрне кабул итү турында имза куелган акт, КС-3 дигән унификацияләнгән форма буенча башкарылган эшләр кыйммәте һәм чыгымнар турында белешмә кәгазе булу;

6. Башка бюджетара трансфертлар алу өчен  Түбән Кама  муниципаль районы җирле үзидарәсенең вәкаләтле органы Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

әлеге Тәртипнең кушымтасында бирелгән форма буенча башка бюджетара трансфертлар бирүгә заявка (алга таба – заявка);

заявкага кул куйган затның вәкаләтләрен раслый торган документ;

әлеге Тәртипнең 5 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән  Түбән Кама муниципаль районының хокукый акты күчермәсе;

билгеләнгән тәртиптә расланган авария-торгызу эшләрен башкаруга локаль смета исәбе;

Россия Федерациясе Статистика буенча дәүләт комитетының «Капиталь төзелештәге эшләрне һәм ремонт-төзелеш эшләрен исәпкә алу буенча беренчел исәпкә алу документациясенең унификацияләнгән формаларын раслау турында» 1999 елның 11 ноябрендәге 100 номерлы карары белән расланган КС-2 дигән унификацияләнгән форма буенча башкарылган эшләрне кабул итү турында акт, КС-3 дигән унификацияләнгән форма буенча башкарылган эшләр кыйммәте һәм чыгымнар турында белешмә кәгазе.

7. Министрлык:

заявканы кергән көнендә теркәүгә ала;

әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документларны заявка теркәлгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә карап тикшерә;

заявка теркәлгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә башка бюджетара трансферт бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итә;

башка бюджетара трансферт бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнелә торган ике көн эчендә башка бюджетара трансферт бирү (бирүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында  Түбән Кама  муниципаль районы җирле үзидарәсенең вәкаләтле органына язма хәбәр бирә.

8. Башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

Түбән Кама  муниципаль районы тарафыннан әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән башка бюджетара трансферт бирү шартлары үтәлмәү;

әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документлар тапшырылмау (тулы күләмдә тапшырылмау);

әлеге Тәртипнең 6 пунктында каралган документлардагы мәгълүмат дөрес булмау.

9. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык тарафыннан башка бюджетара трансфертлар бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә Министрлык белән  Түбән Кама муниципаль берәмлегенең вәкаләтле җирле үзидарә органы арасында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган бертип форма буенча төзелә торган Килешү нигезендә бирелә.

10. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

башка бюджетара трансфертларның максатчан билгеләнеше;

бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме;

башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсенең күрсәткече;

башка бюджетара трансфертларны күчерү тәртибе һәм сроклары;

финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгымнар турында хисап һәм башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсенә ирешү һәм аларга ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турында хисап тапшыру формасы һәм сроклары;

башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсенә ирешмәү нәтиҗәләре;

Түбән Кама муниципаль районы тарафыннан Килешүдә каралган башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;

Килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен якларның җаваплылыгы.

11. Әлеге Тәртипнең 12 пунктында күрсәтелгән авария-торгызу эшләрен башкару башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе булып тора.

Башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсенә ирешү срогы – 2023 елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча.

12. Финанс белән тәэмин итүгә башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгымнар юнәлеше булып түбәндәге авария-торгызу эшләре тора:

күпфатирлы йортта торак урыннарын торгызу (ремонтлау);

күпфатирлы йортта гомуми файдалану урыннарын торгызу (ремонтлау);

тәрәзә уемнарының пыялаларын торгызу.

13. Башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеген бәяләү Министрлык тарафыннан башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәсенең Килешүдә билгеләнгән һәм фактта ирешелгән мәгънәләрен чагыштыру нигезендә гамәлгә ашырыла.

14. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык тарафыннан Килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә Түбән Кама муниципаль районның финанс органына ачылган Түбән Кама муниципаль районы бюджетының бердәм счетына күчерелә.

15. Түбән Кама муниципаль районы җирле үзидарәсенең вәкаләтле органы, 2024 елның беренче 15 эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкка Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган формалар буенча финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгымнар турында хисап һәм башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү һәм аңа ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турында хисап тапшыра.

16. Түбән Кама муниципаль районы җирле үзидарәсенең вәкаләтле органы тапшырыла торган хисап белешмәләренең дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланмаган өчен законнар нигезендә җавап бирә.

17. Әлеге Тәртип нигезендә алынган, 2024 елның 1 гыйнвары хәленә карата файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар 2024 елның беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

18. Башка бюджетара трансфертлар Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына түбәндәге очракларда кире кайтарылырга тиеш:

Түбән Кама муниципаль районы тарафыннан Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары бозылу;

Түбән Кама муниципаль районы җирле үзидарәсенең вәкаләтле органы әлеге Тәртипнең 15 пунктында билгеләнгән срокта финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгымнар турындагы хисапны һәм башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү һәм аңа ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турындагы хисапны тапшырмау;

Килешүдә билгеләнгән срокларда Түбән Кама муниципаль районы тарафыннан башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсенә ирешмәү.

19. Башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланылмаган һәм (яки) Түбән Кама муниципаль районы тарафыннан аларны бирү шартлары бозылган, шул исәптән Түбән Кама муниципаль районы тарафыннан бу Тәртипнең 17 пункты нигезендә акча Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылмаган очракта, аңа карата Россия Федерациясенең бюджет законнарында каралган мәҗбүр итү чаралары кулланыла.

20. Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары бу Тәртип һәм Килешү белән билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

21. Түбән Кама муниципаль районы тарафынанн башка бюджетара трансфертларны максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә башкарыла.

2023 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондыннан Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы бюджетына 2023 елның 25 июлендә көнкүреш газы шартлау нәтиҗәсендә зыян күргән Түбән Кама шәһәре, Вахитов проспекты, 11 йорт адресы буенча күпфатирлы торак йортта авария-торгызу эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә кушымта

Форма

Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры

_______________________________________

___ тан (дан) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)
(муниципаль район җитәкчесе (аның вазыйфаларын башкаручы зат) тулысынча)

Заявка
2023 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондыннан Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы бюджетына 2023 елның 25 июлендә көнкүреш газы шартлау нәтиҗәсендә зыян күргән Түбән Кама шәһәре, Вахитов проспекты, 11 йорт адресы буенча күпфатирлы торак йортта авария-торгызу эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә башка бюджетара трансфертлар бирүгә

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондыннан Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы бюджетына 2023 елның 25 июлендә көнкүреш газы шартлау нәтиҗәсендә зыян күргән Түбән Кама шәһәре, Вахитов проспекты, 11 йорт адресы буенча күпфатирлы торак йортта авария-торгызу эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2023 ел, 27 декабрь, 1692 нче карары белән расланган 2023 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондыннан Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы бюджетына 2023 елның 25 июлендә көнкүреш газы шартлау нәтиҗәсендә зыян күргән Түбән Кама шәһәре, Вахитов проспекты, 11 йорт адресы буенча күпфатирлы торак йортта авария-торгызу эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин

итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 15 декабрь, 2890-б номерлы боерыгы нигезендә бирүегезне сорыйм

______________________________________________________________________________

(муниципаль район исеме)

башка бюджетара трансферт_______________________________________________

(чараның исеме, башка бюджетара трансферт бирү максатлары
)

___________________(____________________________) сум ___ тиен күләмендә.

(сумма цифрлар белән) (сумманы тутырып язу)

Бу заявкада бирелгән белешмәнең дөреслеген һәм тулылыгын раслыйм.

Дөрес булмаган белешмә һәм документлар биргән өчен җаваплылык турында кисәтелдем.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр нәтиҗәләр буенча башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе бозылган очракта, бирелгән бүтән бюджетара трансфертны Татарстан Республикасы бюджеты керемена кайтарырга тиеш булуым турында хәбәрдармын.

___________________________ мөнәсәбәттә гамәлгә ашырырга риза (муниципаль район исеме)
;

______________________________________________________________________________

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерү.

Җитәкче

(аның вазыйфаларын башкаручы зат) ____________/ ________________________________________/

(имза) (Ф.Ис.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

М.У.

Дата: 20__ елның «__» __________

______________________________